**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Түбән Кармалка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге составына керүче
Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак
пунктында (ларында) гражданнар җыены нәтиҗәләре
турында

**28 октябрь 2022 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 28 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2023 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә Түбән Кармалка авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу, триммерлар сатып алу, ротацион элмә чапкыч сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Су белән тәэмин итү урам челтәрен һәм су башняларын ремонтлау (артезиан

скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау һәм буяу, су башняларын буяу, павильон урнаштыру, павильон тышлау, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект - смета документлары өчен түләү, хезмәтләр өчен түләү), Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктларында әлеге эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

- Зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (коймаларны урнаштыру (ремонтлау), чүп савытларын урнаштыру, агачларны кисү, корысарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, хуҗалык инвентаре саклау өчен хуҗалык блогы төзү, керү юлларын, юлларны төзекләндерү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документлары өчен түләү) Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктларында әлеге эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 421 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 220 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 220 кеше тавыш бирде, «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.
Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге составына керүче Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктында (ларында) халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2023 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә Түбән Кармалка авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу, триммерлар сатып алу, ротацион элмә чапкыч сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

- Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам

утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Су белән тәэмин итү урам челтәрен һәм су башняларын ремонтлау (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау һәм буяу, су башняларын буяу, павильон урнаштыру, павильон тышлау, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект - смета документлары өчен түләү, хезмәтләр өчен түләү), Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктларында әлеге эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

- Зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (коймаларны урнаштыру (ремонтлау), чүп савытларын урнаштыру, агачларны кисү, коры-сарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, хуҗалык инвентаре саклау өчен хуҗалык блогы төзү, керү юлларын, юлларны төзекләндерү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документлары өчен түләү) Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктларында әлеге эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Түбән Кармалка авылы, Ленин урамы, 44 нче йорт, Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге башлыгы А.Ф.Митякин